ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

Приказ | Казан шәһәре | Боерык

04.07.2024 | № 185 - тә

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турындагы кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне һәм аның составын раслау турында

«Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә

боерам:

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турындагы кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар

буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турындагы кушымта итеп бирелгән Комиссия составын расларга.

3. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 23 августындагы 244-од номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Р.М. Мотахаровка йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Шәрәфетдинов

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының елның 04.07.2024 185-тә номерлы боерыгы белән расланган

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә эшләнгән.

Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияне (алга таба –Комиссия) формалаштыру һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. Үз эшчәнлегендә Комиссия Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы түбәндәгеләргә ярдәм итү:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре, Комитет) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар белән ришвәтчелеккә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәвен тәэмин итүдә (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр);

Комитетта ришвәтчелекне кисәтү чаралары күрүдә.

1.4. Комиссия Комитетта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте

вазыйфаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфаларын) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карый (билгеләү һәм аннан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче Комитет рәисе урынбасарыннан тыш).

1.5. Комитетта билгеләү һәм аннан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында оештырылган хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Комиссия тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турында хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр үткәрми.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия составына Комитет рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан билгеләп куела торган комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм әгъзалары керә (алга таба – рәис). Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаган вакытта аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) Комитет рәисе урынбасары (Комиссия рәисе), хокук эше буенча әйдәп баручы киңәшче, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөдире, ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат (Комиссия секретаре), Комитетның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, Комитет рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) билгеләгән Комитетның структур бүлекчәләре дәүләт хезмәткәрләре;

б) Ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе вәкиле;

в) фәнни оешмаларның, һөнәри белем бирү оешмаларының, югары белем бирү оешмаларының һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле вәкиле (вәкилләре).

2.3. Комитет рәисе Комиссия составына түбәндәгеләрне кертү турында карар кабул итәргә мөмкин:

а) Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилен;

б) Комитетта күрсәтелгән оешма төзелгән очракта, ветераннарның иҗтимагый оешмасы вәкилен;

в) Комитетта билгеләнгән тәртиптә эшләүче профсоюз оешмасы вәкилен.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комитет рәисе соравы нигезендә тиешле органнар һәм оешмалар белән килешү буенча билгеләнгән тәртиптә Комиссия составына кертелә. Килештерү сорау алган көннән алып 10 көн эчендә башкарыла.

2.5. Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләмәгән Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының дүрттән бер өлешеннән ким булмаска тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия кабул иә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Комиссия утырышларында киңәшмә тавышы хокукы белән түбәндәгеләр катнаша:

а) аңа карата Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә торган, Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче, Комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре биләгән шундый ук вазыйфаларны биләүче ике дәүләт хезмәткәре;

б) Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссия караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә ала торган белгечләр;

башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары; кызыксынган оешмалар вәкилләре; Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәре вәкиле – һәр конкрет очракта Комиссия утырышы көненә кадәр кимендә өч көн элек Комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенече нигезендә аерым кабул ителә торган Комиссия рәисенең карары буенча.

2.8. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән ике өлеше булса, хокуклы дип санала. Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар үткәрү рөхсәт ителми.

2.9. Комиссия әгъзасының турыдан-туры яки читләтеп Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килсә, бу хакта ул утырыш башланганчы белдерергә тиеш. Бу очракта комиссиянең тиешле әгъзасы әлеге мәсьәләне карауда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый

актлары нигезендә уздырылган дәүләт хезмәткәре тәкъдим иткән мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәвен тикшерү нәтиҗәләре буенча Комитет рәисе тарафыннан түбәндәгеләр хакындагы тикшерү материалларын тәкъдим итү:

дәүләт хезмәткәренең Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында нигезләмә каралган дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат тапшыруы турында;

дәүләт хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында;

б) Комитетның норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторына ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы затка кергән:

Татарстан Республикасының Комитетта дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән, аны биләгәндә дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмаларда вазыйфа биләүгә яки коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешмаларда гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга ризалык бирү турында гаризасы, әгәр бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел узганчы;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирә алмау турындагы гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата средстволарны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен кулга алу, чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан территориясендә счетлар (вкладлар) булган, чит ил банкында акчалата средстволар һәм кыйммәтле әйберләр саклана һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган әлеге чит ил дәүләтенең законнары нигезендә кертелгән боерыкларны тыю белән бәйле рәвештә, яисә аның ихтыярына, хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар аркасында үтәү мөмкин түгеллеге турында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр

каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәрнамәсе;

в) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүне тәэмин итүенә яки Комитетта ришвәтчелекне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруга кагылышлы Комитет рәисенең яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының тәкъдиме;

г) Комитет рәисенең дәүләт хезмәткәренең «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1 өлешендә каралган дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат бирүен раслый торган тикшерү материалларын тәкъдим итүе;

д) «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлешенә (алга таба – 273-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $64^1$ статьясы нигезендә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешманың Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамә төзүе турында Комитетка кергән хәбәрнамәсе, әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарәсе аерым функцияләре аның Комитетта вазыйфаны биләгәндә башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, Комиссия тарафыннан күрсәтелгән гражданны әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә кертүдән элек баш тарту яисә мондый гражданга коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмаларда вазыйфа биләүгә яки коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмаларда гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга ризалык бирү мәсьәләсе Комиссия тарафыннан каралмаган шарты белән;

е) хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулый торган аңа бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү турында дәүләт хезмәткәренең хәбәрнамәсе.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторына ришвәтчелекне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туган көне, яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешманың атамасы, урнашу урыны, аның эшчәнлеге характеры, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгәндә граждан тарафыннан башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмаларга карата дәүләт идарәсе буенча функцияләре, шартның төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), аның күздә тотылган гамәлдә булу вакыты, шартнамә буенча эш (хезмәтләр) үтәгән (күрсәткән) өчен түләү суммасы.

Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторында ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан мөрәҗәгатьне

карау гамәлгә ашырыла, аның нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгатьнең асылы буенча «Ришвәтчелеккә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, дәлилләнгән нәтиҗә әзерләнә.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне дәүләт хезмәтеннән азат ителүне планлаштыручы дәүләт хезмәткәре бирә ала һәм, ул әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә Комитетның ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы дәүләт хезмәте секторы вазыйфаи заты тарафыннан карала, Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен үтәве турында дәлилләнгән нәтиҗә әзерләүне гамәлгә ашыра.

3.4.1. әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы, хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилле нәтиҗә әзерләүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи заты тарафыннан карала.

3.4.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау яисә Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә әзерләгәндә, Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы заты мөрәҗәгать яки хәбәр биргән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә, һәм аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен, Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга, шул исәптән ришвәтчелеккә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, соратулар җибәрелергә мөмкин. Мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә яки башка материаллар, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә алынганнан соң, җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гаризалар җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки хәбәрнамә алынганнан соң, 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Билгеләнгән вакыт Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артык түгел.

3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан соратулар нигезендә алынган мәгълүмат;

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче

абзацларында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр һәм хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән йомгак, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.19 пунктлары яисә башка карар нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.

3.5. Комиссия рәисе, аңа Комиссия утырышын уздыру өчен нигезләр булган мәгълүмат кергәндә:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы датасы, әлеге Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңга калып билгеләнә алмый;

б) Комиссия тарафыннан аңа карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә кергән мәгълүмат белән, шулай ук күрсәтелгән мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) Комиссия утырышына әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенечнамәләрне карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау турында (караудан баш тарту турында) карар кабул итә.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт граждан хезмәткәре яисә Комитетта дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән граждан катнашында уздырыла. Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында дәүләт граждан хезмәткәре яки граждан әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчалары нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрнамәдә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәре яки граждан булмаганда түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки хәбәрнамәдә дәүләт гоаждан хезмәткәренең яки гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга нияте турында күрсәтмә булмаса;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр ителгән дәүләт хезмәткәре яки граждан

Комиссия утырышына килмәсә.

3.9. Комиссия утырышында Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт хезмәткәре яки граждан (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләр буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында аларга билгеле булган мәгълүматларны сөйләргә хокуклы түгел.

3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» пунктчасындагы икенче абзацта күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тәкъдим иткән белешмәләр 2009 елгы no УП-702, ышанычлы һәм тулы дип билгеләргә;

б) б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан әлеге пунктның «а» пунктчасында аталган Нигезләмә нигезендә тапшырылган мәгълүматлар дөрес түгел һәм (яки) тулы түгел дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Комитет рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата аерым бер җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а» пунктчасындагы өченче абзацта күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәгәнен билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәмәгәнен билгеләргә; Бу очракта Комиссия Комитет рәисенә дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне бозуның рөхсәт ителмәвен күрсәтергә яки дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.13. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яки коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга ризалык бирергә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә;

б) гражданга коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яки коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга ризалык бирүдән баш тартырга, әгәр

әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, һәм үзенең баш тартуын дәлилләргә.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы өченче абзацта күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү сәбәбе объектив һәм нигезле дип таныrga;

б) дәүләт хезмәткәренә үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү сәбәбе нигезле түгел дип танырга; Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыру буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән мәгълүматларны тапшырудан качу ысулы булып тора, дип танырга. Бу очракта Комиссия Комитет рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата аерым бер җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.15. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы дүртенче абзацта күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата средстволарны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы шартлар объектив һәм нигезле, дип танырга;

б) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата средстволарны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы шартлар объектив һәм нигезле түгел, дип танырга. Бу очракта Комиссия Комитет рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата аерым бер җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.15.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндәге шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин, дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) Комитет рәисенә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки аның барлыкка килүенә юл куймау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән, дип таныргa. Бу очракта Комиссия Комитет рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата аерым бер җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «в» пунктчасында каралган мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

3.17. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар дөрес һәм тулы, дип таныргa;

б) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар дөрес түгел һәм (яки) тулы түгел, дип таныргa. Бу очракта Комиссия Комитет рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тоту нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) аларның компетенциясе нигезендә башка дәүләт органнарына җибәрергә тәкъдим итә.

3.18. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада граж'дан тарафыннан вазыйфа биләүгә яки коммерцияле яисә коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга ризалык бирергә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә;

б) гражданның хезмәт килешүе шартларында коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләве һәм (яки) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эш башкаруы (хезмәт күрсәтү) 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен бозуын билгеләргә. Бу очракта Комиссия Комитет рәисенә әлеге хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәрнамә биргән оешмага хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын таныргa;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт

тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын таныргa.

3.20. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г» һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, моңа нигезләр булганда, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11 - 3.15.1, 3.17 - 3.19 пунктларында каралганнан башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.21. Комиссия карарларын үтәү өчен, Комитетның норматив хокукый актлары, Комитет рәисе карарлары яки йөкләмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә Комитет рәисенә карауга тапшырыла.

3.22. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә) Комиссия әгъзаларының утырышта катнашучы гади күпчелек тавышлары белән кабул ителә.

3.23. Комиссия карарлары аның утырышында катнашкан Комиссия әгъзалары имзалаган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карардан тыш, Комитет рәисе өчен тәкъдим итү характерында. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри характерда.

3.24. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) Комиссия утырышында карала торган мәсьәләләрнең, аңа карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), вазыйфасын күрсәтеп, һәрберсенең формулировкасы;

в) дәүләт хезмәткәренә карата белдерелгән дәгъвалар, алар нигезләнгән материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларга аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезләрне үз эченә алган мәгълүмат чыганагы, Комитетка мәгълүматның керү датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итү нигезләмәсе.

3.25. Комиссия карары белән килешмәгән Комиссия әгъзасы үз фикерен язма

рәвештә әйтергә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушылырга тиешле, һәм дәүләт хезмәткәре аның белән танышырга тиеш.

3.26. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш көненнән алып 7 көн эчендә Комитет рәисенә, тулысынча яки аннан өзекләр рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча башка кызыксынган затларга җибәрелә.

3.27. Комитет рәисе Комиссия утырышы беркетмәсе карарга тиеш һәм үз компетенциясе чикләрендә, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын дәүләт хезмәткәренә карата куллану турында карар кабул иткәндә, шулай ук ришвәтчелеккә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча андагы тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы.

Комиссиянең тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында Комитет рәисе Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән алып бер ай эчендә Комиссиягә язма рәвештә хәбәр итә. Комитет рәисе карары Комиссиянең алдагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышусыз игътибарга алына.

3.28. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар хокук бозу билгеләре ачыкланган очракта, бу хакта мәгълүмат Комитет рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсен хәл итү өчен тапшырыла.

3.29. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләре яки җинаять составы булган гамәл (гамәл кылмау факты) башкару факты билгеләнгән очракта, Комиссия рәисе әлеге гамәлнең (гамәл кылмауның) башкарылуы турында мәгълүматны һәм мондый фактны раслый торган документларны хокук куллану органнарына 3 көн эчендә, ә кирәк булганда шунда ук тапшырырга тиеш.

3.30. Комиссия утырышыберкетмәсенең күчермәсе яки аннан өземтә аңа карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә кушыла.

3.31. Комиссия секретаре имзасы һәм Комитет мөһере белән расланган Комиссия карарыннан өзек Комитетта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, аңа карата әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга кул куйдырып тапшырыла, яки Комиссиянең тиешле утырышы уздырылган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча хәбәрнамә белән заказ хаты белән җибәрелә.

3.32. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырышны үткәрүнең датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышу өчен тәкъдим ителә торган материаллар белән таныштыру кКомитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторының ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы заты тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының елның 04.07.2024 185-тә номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| 1. Мотахаров Радик Мансур улы | Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары – комиссия рәисе; |
| 2. Ковкрак Петр Владимирович | Хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аеруча саклана торган табигый территорияләр өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге идарәсе башлыгы – комиссия рәисе урынбасары; |
| 3. Корнилов Юрий Владимирович | Татарстан Республикасы Рәисе идарәсенең Ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча оештыру бүлегенең баш киңәшчесе (килешү буенча); |
| 4. Варфоломеева Вероника Николаевна | Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының хокукый тәэмин итү буенча әйдәп баручы киңәшчесе; |
| 5. Филиппова Оксана Александровна | Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөдире,ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы зат – комиссия секретаре; |
| 6. Башкирцева Светлана Анатольевна | «Россия дәүләт гадел хөкем университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү учреждениесенең Казан филиалында судьяларның, судларның дәүләт граждан хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү факультеты һәм Суд департаменты деканы, икътисад фәннәре кандидаты (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| 7. Гогин Валерий Алексеевич | «Татар агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институты» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе доценты, техник фәннәр кандидаты, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча) |